РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 21 ноябре** **Чистай шәһәре** **№36/3**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
2020 елның 29 декабрендәге
5/2 номерлы карарының
гамәлдә булуын туктатып
тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең 1.3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2024 елның 26 сентябрендәге 34/3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенәО.В.Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И. Ксенофонтов